МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
420014, Казань, ул.Федосеевская, д.36

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ
420014, Казан ш., Федосеевская ур., 36 йорт

Тел.(843) 221 76 00, факс (843) 221 76 79, E-mail: agro@tatar.ru

**П Р И К А З** **БОЕРЫК**

23.05.2014 г.Казань № 103/2-пр

**Коррупциягә каршы көрәшкә бәйле рәвештә биләнә торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон,«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнеп куелганда һәм биләгәндә, гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр һәм үзенең иренең (хатынының), балигъбулмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-701 номерлы Указын үтәү йөзеннән

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Коррупциягә каршы көрәшкәбәйле рәвештә биләнә торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга (кушымта итеп бирелә). Исемлек нигезендә, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнеп куелганда, гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үзенең иренең (хатынының), балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш, шулай ук Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте

вазыйфаларын биләгәндә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үзенең иренең (хатынының), балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алу буенча алыш-бирешләрнең һәркайсыннан алынган үз керемнәре, шулай ук үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр тапшырырга тиеш, әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкару алдындагы өч елның гомуми кеременнән артып китсә, алыш-биреш башкарырлык кергән акчаларның чыганаклары турында да белешмәләр бирергә тиеш, дип билгеләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соң, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе ризалыгы белән, ике ел буе оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфа биләргә һәм (яисә) шул оешмада бер ай буе граждан-хокук шартнамәсе (граждан-хокук шартнамәләре) шартларында йөз мең сумнан артыграк хактагы эшләр башкарырга (шул оешмага хезмәтләр күрсәтергә) хокуклы, әгәр әлеге оешманың аерым дәүләт идарә органнары функцияләре Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел буе әлеге боерыкның 3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокук шартнамәләре төзегәндә яллаучыга (эш бирүчегә) үзенең соңгы хезмәт урыны турында белешмәләр бирергә тиеш;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң әлеге боерыкның 3 пунктындагы өченче абзацында каралган таләпләрне үтәмәсә, шушы граждан белән әлеге боерыкның 3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) төзелгән хезмәт яисә граждан-хокук шартнамәсе туктатыла.

4. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2010 елның 27 гыйнварындагы 8/2-пр номерлы һәм «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2010 елның 27 гыйнварындагы 8/2-прномерлы боерыгына үзгәреш кертү турында» 2010 елның 3 сентябрендәге 150/2-пр номерлы боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерыкны 2014 елның 30 июленә кадәр Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасарларына, структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары М.А. Җәббаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының 2014
елның 23 маендагы 103/2-пр номерлы
боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында коррупциягә каршы көрәшкә бәйле рәвештә биләнә торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Финанслау бүлегенең Татарстан Республикасы бюджетын үтәү секторы әйдәүче киңәшчесе
2. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторы әйдәүче киңәшчесе
3. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторы әйдәүче белгече
4. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторының 1 разрядлы өлкән белгече
5. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторының 1 разрядлы белгече
6. Аудит һәм коррупциягә каршы эшләр бүлеге әйдәүче консультанты 7. Аудит һәм коррупциягә каршы эшләр бүлеге әйдәүче белгече
8. Инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлегенең дәүләт заказы секторы әйдәүче белгече
9. Хезмәтне саклау секторының 1 разрядлы өлкән белгече
10. Азык-төлек базарын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе
11. Игенчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе
12. Игенчелек тармакларын үстерү бүлегенең бөртекле һәм техник культуралар секторы әйдәүче киңәшчесе
13. Орлыкчылык һәм химияләштерү секторының әйдәүче киңәшчесе
14. Терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе
15. Терлекчелек комплексларын үстерү секторының әйдәүче киңәшчесе 16. Ит җитештерү секторыныңәйдәүче киңәшчесе
17. Икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлегенең әйдәүче киңәшчесе 18. Предприятиеләрнереструктуризацияләү һәм агробизнесны үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе
19. Предприятиеләрне реструктуризацияләү һәм агробизнесны үстерү бүлегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, крестьян-фермер хуҗалыкларын һәм кооперативларны үстерү секторы әйдәүче белгече
20. Предприятиеләрне реструктуризацияләү һәм агробизнесны үстерү бүлегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, крестьян-фермер хуҗалыкларын һәм кооперативларны үстерү секторы әйдәүче консультанты
21. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегенең әйдәүче киңәшчесе
22. Агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе
23. Терлекчелек объектларын һәм энергия ресурсларын механикалаштыру секторының әйдәүче белгече
24. Техник җиһазландыру секторының 1 разрядлы өлкән белгече